**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11786**
**04.12.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау системасы турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү объектларының һәм системаларының куркынычсыз эшләвен тәэмин итү һәм аларда гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмау максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы Приказы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау системасы турында нигезләмәне (алга таба-нигезләмә) кушымтада каралганча расларга.
2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинг үткәргәндә җылылык белән тәэмин итү оешмаларына нигезләмәгә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 4 декабрендәге
11786 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау системасы турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы Карары нигезендә эшләнгән һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасы торышына мониторинг үткәрү тәртибен билгели.

2. Җылылык белән тәэмин итүне мониторинглау системасын булдыру һәм аны эшләтү максатлары булып җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру, авария хәлләрен кисәтү, булдырмый калу, ачыклау һәм бетерү буенча чараларны гамәлгә ашыру аша авария-торгызу эшләрен башкаруга чыгымнарны киметү тора.

3. Нигезләмә җылылык белән тәэмин итү системасын мониторинглау системасын булдырганда һәм эшләткәндә җирле үзидарә органнарының, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның һәм җылылык энергиясен кулланучыларның үзара эшчәнлеген билгели.

4. Әлеге нигезләмә торак-коммуналь хезмәтләрне башкаручылар һәм кулланучылар өчен мәҗбүри.

2. Төп төшенчәләр

5. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглау – җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының торышын күзәтү, бәяләү һәм прогнозлауның комплекслы системасы (алга таба – мониторинг);

кулланучы – коммуналь хезмәтләрне шәхси, гаилә, йорт һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен кулланучы граждан;

идарәче оешма – оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүче юридик зат, шулай ук шәхси эшмәкәр;

коммуналь хезмәтләр – гражданнарның торак биналарда уңайлы яшәү шартларын тәэмин итә торган салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су бүлү, электр белән тәэмин итү һәм җылыту буенча хезмәтләр күрсәтү буенча хезмәтләр башкаручының эшчәнлеге;

ресурслар белән тәэмин итүче оешма – оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, коммуналь ресурсларны сатуны гамәлгә ашыручы юридик зат, шулай ук шәхси эшмәкәр;

коммуналь ресурслар-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган кайнар су, салкын су, җылылык энергиясе, электр энергиясе;

җылылык белән тәэмин итү системасы – шәһәрнең (районның), торак пунктның билгеләнгән тәртиптә тиешле махсус рөхсәтләр (лицензияләр) алган, торак-коммуналь хуҗалыкның җылылык белән тәэмин итүче оешмасы тарафыннан эксплуатацияләнә торган гомуми җитештерү процессы белән берләштерелгән җылылык чыганаклары һәм (яки) җылылык челтәрләре җыелмасы;

җылылык челтәре – кулланучыларга җылылык энергиясен тапшыру һәм бүлү өчен билгеләнгән җайланмалар җыелмасы;

җылылык пункты – җылылык челтәрләренә җылылык, вентиляция, һава кондиционерлары, кайнар су белән тәэмин итү системаларын һәм сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләренең, торак һәм иҗтимагый биналарның җылылык кулланучы технологик җайланмаларын тоташтыру өчен билгеләнгән җайланмалар җыелмасы (индивидуаль- бер бинаның яки аның бер өлешенең җылылык куллану системаларын тоташтыру өчен; үзәк – шул ук, ике бина яки аннан да күбрәк);

техник хезмәт күрсәтү – эшләнмә (җайланма) билгеләнеше, сакланышы яки транспортировкасы буенча кулланылганда, аның эшчәнлеген яки төзеклеген саклау буенча операцияләр комплексы яки операция;

агымдагы ремонт – объектның аерым тиз туза торган состав өлешләрен һәм детальләрен алыштыру һәм (яки) торгызу юлы белән техник һәм икътисадый характеристикаларын билгеләнгән чикләрдә саклау өчен башкарыла торган ремонт;

капиталь ремонт – объектның теләсә нинди состав өлешләрен алыштыру яки торгызу юлы белән техник һәм икътисадый характеристикаларын проектка якын зурлыкларга кадәр торгызу өчен башкарыла торган ремонт;

технологик бозылулар – нәтиҗәләрнең характерына һәм авырлыгына бәйле рәвештә, җылылык белән тәэмин итү системасы эшендә һәм эксплуатацияләүче оешмаларның эшендә бозылулар (персоналга тәэсир итү; энергия йөрткечнең параметрлары тайпылу; экологик йогынты; җиһазларга зыян килү күләме; ышанычлылыкны киметүнең башка факторлары) инцидент һәм авариягә бүленә;

инцидент – җиһазлар һәм (яки) челтәрләрнең эшләүдән туктавы яки зарарлануы, билгеләнгән режимнардан тайпылу, җитештерү объектында эш алып бару кагыйдәләрен билгеләүче федераль законнарны, норматив - хокукый актларны һәм техник документларны бозу, шул исәптән:

- технологик тоткарлык – җиһазларның җылылык энергиясен җитештерү процессын һәм (яисә) кулланучыларга тапшыруны бозуга китергән мәҗбүри өзелүе яки эшкә сәләтлелеге чикләнү, әгәр аларга авария билгеләре хас булмаса;

- функциональ тоткарлык – җиһазларның җылылык энергиясен җитештерү процессына һәм (яисә) кулланучыларга тапшыруга йогынты ясамаган төзексезлеге (шул исәптән резерв һәм ярдәмче җиһазларның), шулай ук саклау чараларының һәм автоматиканың дөрес эшләмәве, персоналның хаталы гамәлләре, әгәр алар кулланучыларны чикләүгә һәм бирелә торган энергиянең сыйфатын киметүгә китермәсә.

- җылылык белән тәэмин итү объектларындагы авария - җылылык белән тәэмин итү системалары, челтәрләре һәм чыганаклары элементларының эшләмәве, шуның нәтиҗәсендә кулланучыларга һәм абонентларга җылылык энергиясен бирү 12 сәгатьтән артык булмаган һәм кайнар су белән тәэмин итү 36 сәгатьтән артык булмаган чорга туктатылып тору;

ватыклык – җылылык белән тәэмин итү системасы эшендә технологик процесс белән билгеләнгән таләпләрнең берсе булса да үтәлми торган башка кимчелекләр.

## 3. Мониторингның төп бурычлары

6. Җылылык белән тәэмин итү системасы торышын мониторинглауның төп бурычлары булып тора:

- җылылык белән тәэмин итү объектларының торышы, җылылык белән тәэмин итү системаларында барлыкка килә торган аварияләр һәм ватыклыклар һәм аларда үткәрелә торган ремонт эшләре турында мәгълүматлар җыю, эшкәртү һәм анализлау;

- җылылык челтәрләрендә ремонт эшләрен үткәрү планнарын төзү процессын оптимальләштерү;

- җылылык челтәрләрен карап тотуга һәм аларда ремонт эшләре үткәрүгә финанс чараларын бүлеп бирүне нәтиҗәле планлаштыру.

7. Мониторинг системасы үз эченә ала:

- мәгълүматлар җыю;

- мәгълүматны саклау, эшкәртү һәм тәкъдим итү;

- карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

8. Мәгълүматлар җыю.

Җылылык челтәрләренең торышына мониторинг мәгълүматларын җыю системасы муниципаль берәмлек территориясендәге җылылык челтәрләрен күзәтүнең гамәлдәге барлык ысулларын берләштерә.

Мәгълүматлар җыю системасына үткәрелгән ремонтлар буенча мәгълүматлар һәм эксплуатация персоналы туплаган мәгълүматлар кертелә.

Түбәндәге мәгълүмат җыела:

- җылылык челтәрләре прокладкалары технологик җиһазларының мәгълүмат базасы;

- электрон рәвештә башкару документациясе (җылылык үткәргечләр схемалары);

- җылылык белән тәэмин итү объектларында уздырылган ремонт турында белешмәләр;

- төзелеше тәмамланган, киңәйтелгән, реконструкцияләнгән, яңадан техник җиһазландырылган җылылык белән тәэмин итү объектларын файдалануга тапшыру турында мәгълүматлар;

- объектның исемен, объектның адресын, авария хәленә китергән сәбәпләрне, авария хәлен бетерү буенча кабул ителгән чараларны күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү объектларында барлыкка килә торган, шулай ук кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүдән читләштергәндә - өзү чорын һәм өзелгән кулланучылар исемлеген күрсәтеп, авария ситуацияләрен исәпкә алу реестры.

9. Мәгълүматлар җыю Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә оештырыла һәм Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең җылылык белән тәэмин итү схемасын эшләү өчен туплана.

10. Карар кабул итү өчен мәгълүматны анализлау һәм бирү.

Җылылык челтәрләрендә мәгълүматны анализлау һәм бирү системасы, бирелгән финанслау күләменнән чыгып, зыян күргән челтәрләрдән иң ышанычсызларын сайлап алу нигезендә ремонт планнарын оптимальләштерү бурычын хәл итүгә юнәлдерелгән.

Мәгълүматларны статистик эшкәртү өчен төп мәгълүмат чыганагы булып ремонт чорында диагностикалау һәм җылылык челтәрләрен ремонтлауны һәм алмаштыруны планлаштыруның төп ысулы буларак кулланыла торган опрессовка нәтиҗәләре тора.

Мониторинг мәгълүматлары, объектның чын торышын ачыклау, ялган мәгълүматка юл куймау һәм оптималь идарә итү карары кабул итү максатларында, объектның актуаль паспорт характеристикаларына салына.

## 4. Мониторинг системасы эшчәнлеге

11. Мониторинг системасы эшчәнлеге объект һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

12. Объект дәрәҗәсендә мониторинг системасы эшчәнлегенә оештыру-методик җитәкчелек итүне һәм аны координацияләүне җылылык белән тәэмин итү объектларын эксплуатацияләүче оешмалар гамәлгә ашыра.

13. Муниципаль дәрәҗәдә мониторинг системасы эшчәнлегенә оештыру-методик җитәкчелек итүне һәм аны координацияләүне ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенең бердәм дежәр-диспетчерлык хезмәте, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 5. Мониторингның төп принциплары

14. Мониторингның төп принциплары булып тора:

- җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының техник торышы турында мәгълүмат алуның законлылыгы;
- җылылык челтәрләренең һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының техник торышын өзлексез күзәтү;
- мониторинг нәтиҗәләреннән һәркем файдалана алырлык булу;
- мониторинг нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларның дөреслеге.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева